ГЛАВА БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Байряки-Тамак, ул.Новая, д.37,
423964,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ-ТАМАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урамы,
37 йорт, 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail: Btam.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№2 09 ноябрь 2021 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге башлыгының 2021 елның 8 ноябрендәге «2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк торак пунктында халык җыенын үткәрү турында»гы 1 санлы карарын гамәлдән чыгару турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 45-ХРТ санлы Татарстан Республикасы законы, 2021 елның 28 октябрендәге «Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау чаралары турында «2020 елның 19 мартындагы 208 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы 1006 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, 2019 елның 17 июлендә Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге Советының 8 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан республикасы Ютазы муниципаль районы "Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы, 2019 елның 28 октябрендә Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге Советының 19 санлы карары белән кабул ителгән «Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында» нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау максатыннан

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге башлыгының 2021 елның 8 ноябрендәге «2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк торак пунктында халык җыенын үткәрү турында»гы 1 санлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.
3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге башлыгы Ф.В. Әхмәтов